Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXII-6**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 23 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, “Россия Федерациясенең аерым закон актларына дәүләт хезмәте өлкәсендә коррупциячел хокук бозулар кылган өчен ышаныч югалу белән бәйле эштән азат итү рәвешендә түләтүне куллану турында мәгълүматлар урнаштыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында” 2017 елның 1 июлендәге 132-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2017 елның 26 июлендәге 192-ФЗ номерлы федераль законнарга таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 22 июлендәге XXVII-6 номерлы, 14 август 2014 ел XXXIX-3, 13 декабрь 2014 ел XLII-8, 14 ноябрь 2015 ел V-3, 23 апрель 2016 ел X-8, 16 ноябрь 2016 ел XIII-9, 29.05.2017 ел XIX-9 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6.1 маддәнең 10 пунктына түбәндәге сүзләрне өстәргә:

“-күрсәтелгән бәяләмәгә шикаять бирү өчен билгеләнгән срок тәмамланган көннән алып 10 ел эчендә Россия Федерациясенең тиешле субъекты чакыру комиссиясенә, ә күрсәтелгән бәяләмәгә һәм (яисә) Россия Федерациясенең тиешле субъекты чакыру комиссиясе карарына карата гражданның күрсәтелгән бәяләмәсенә карата шикаять белдерелгән булса - суд карары законлы көченә кергән көннән алып 10 ел эчендә гражданның күрсәтелгән бәяләмә һәм (яисә) Россия Федерациясе субъектының тиешле чакырылыш комиссиясе карары чыгарылганда гражданның күрсәтелгән бәяләмәгә шикаяте буенча хокуклары бозылмаган дип танылган суд карары законлы көченә кергән көннән алып 10 ел эчендә”;

2) 19.1 бүлегенә түбәндәге эчтәлектәге 19.15 маддәне өстәргә:

“19.15 Муниципаль хезмәткәргә ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендә түләтүләр куллану турындагы мәгълүматлар муниципаль хезмәт узган җирле үзидарә органы тарафыннан “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсендә каралган ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затлар реестрына кертелә.”.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәнең 6.1 маддәсендәге 10 пункты нигезләмәләре (әлеге карар редакциясендә) 2014 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар, карарның 1 пунктының 2 пунктчасыннан гайре, рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасы 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г. Вәлиев